ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ
2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында
Сөйки авыл җирлегенең Сөйки авылында
Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы

2024 елның 28 октябре №__1__

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Сөйки авылында гражданнар җыены карар кабул итте::

1.2025 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Сөйки авыл җирлегенең Сөйки авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә::

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- яр буе зоналарын, сулыкларны чистарту;
- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;
- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыклары төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү.

3. Әлеге карарны адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.:

- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, кызылармеец ур., Авыл үзәге;
- ТР Кама Тамагы районы Сөйки авылы, Колхоз урамы, 16А йорт, китапханә бинасы; шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Сойки авыл җирлеге Башлыгы: П.В. Сорокин